| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**БОЕРЫК**

| 19.02.2019 | Казан шәһәре | № 31-од |
|---|---|---|

«Минем нәселем»
республика генеалогик тикшеренүләр
конкурсы турында

Нәсел традицияләрен саклап калу һәм үстерү, гаилә элемтәләрен һәм буыннан алмашын ныгыту, Татарстан һәм үз гаиләң тарихы белән кызыксынуны арттыру, тарихи аң булдыру һәм ватанпәрвәрлек хисләрен тәрбияләү, шулай ук архив материаллары белән эшләүгә, тарихи һәм туган якны өйрәнү әдәбиятын укуга җәлеп итү максатларында БОЕРЫК БИРӘМ:

1. «Минем нәселем» республика генеалогик тикшеренүләр конкурсын оештырырга һәм 2019 елның 20 мартыннан 30 апреленә кадәр үткәрергә.
2. Кушымта итеп бирелгән 2019 елда «Минем нәселем» республика генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында нигезләмәне расларга.
3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис Г. З. Габдрахманова

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының
2019 елның 19 февралендәге 31-од номерлы боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

2019 елда «Минем нәселем" республика
генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2019 елда «Минем нәселем» республика генеалогик тикшеренүләр конкурсын үткәрү турында әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, конкурс) конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибен, конкурс эшләрен бәяләү критерийларын билгели.

1.2. Конкурсны оештыручы – Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (алга таба – ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты).

1.3. Конкурс 2019 елның 20 мартыннан 30 апреленә кадәр үткәрелә.

1.4. Конкурста катнашу өчен сайлап алу вакыты, шартлары һәм критерийлары турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайтына (http://arhiv.tatarstan.ru) (алга таба – ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайты) «2019 елда «Минем нәселем» республика генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында» ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы үз көченә кергән көннән 3 эш көне эчендә урнаштырыла.

## II. Конкурсның максаты һәм бурычлары

2.1. Конкурсның төп максаты – гаилә-нәселләр гореф-гадәтләрен торгызу, гаилә кыйммәтләрен саклап калуга ярдәм итү.

2.2. Конкурсның бурычлары:

нәсел гореф-гадәтләрен саклап калу һәм үстерү;

гаилә тарихының ил һәм туган як тарихына катнашы булуын өйрәнеп, балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирүгә булышлык күрсәтү;

гаилә традицияләрен һәм буыннар арасындагы элемтәләрне ныгытуга ярдәм итү;

тарихны һәм нәселләрне өйрәнү традицияләрен саклап калу һәм үстерү;

архив материаллары белән эшләүгә, тарихи һәм туган якны өйрәнү әдәбиятын укуга җәлеп итү.

## III. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста биш яшь төркемнәре буенча теләгән һәркем катнаша ала:

1 төркем – гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 сыйныф укучылары;

2 төркем – гомуми белем бирү оешмаларының 5-8 сыйныф укучылары;
3 төркем – гомуми белем бирү оешмаларының 9-11 сыйныф укучылары;
4 төркем – һөнәри белем бирү оешмаларының 18 яшькә кадәрге укучылары;
5 төркем – 18 яшьтән өлкәнрәк физик затлар.

3.2. Конкурста җиңүчеләр һәр яшь төркеме буенча аерым билгеләнә.

3.3. Конкурста катнашуга 16 яшьтән яшьрәк катнашучы гаризасы катнашучы ата-анасының берсе (яки законлы вәкиле) тарафыннан имзалана.

3.4. Конкурска, 1 яшь төркемендә катнашучылардан тыш, бары тик индивидуаль башкарылган эшләр генә кабул ителә.

## IV. Конкурсны оештыру комитеты

4.1. Конкурс үткәрү һәм эшләрне сайлап алу өчен Татарстан Республикасының һәр муниципаль районында (шәһәр округында) муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитетының архив бүлеге (идарәсе) вәкилләреннән, музей хезмәткәрләреннән, фәнни белгечләрдән жюри функцияләре белән (конкурс эшләрен бәяләү, муниципаль дәрәҗәдә (шәһәр дәрәҗәсендә), яшь төркемнәренә карап, катнашучылар рейтингын төзү һәм сайлап алу) район (шәһәр) оештыру комитетлары төзелә.

4.2. Конкурсны оештыру, үткәрү һәм нәтиҗәләр чыгару өчен ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты, «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесе вәкилләреннән рәис, рәис урынбасары һәм оештыру комитеты әгъзалары составында алты кешелек республика оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) төзелә.

4.3. Оештыру комитеты функцияләре:

конкурсның оештыру эшләре буенча әзерлеген һәм үткәрелүен тәэмин итү;

муниципаль районнарның (шәһәр округларының) башкарма комитетлары архив бүлекләре (Идарәләре) тарафыннан сайлап алынган конкурс гаризаларын туплау;

массакүләм мәгълүмат чараларында, «Татарстан Республикасы архивлары» порталында һәм ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты сайтында конкурс барышы турында хәбәр итү;

жюри беркетмәсе нигезендә җиңүчеләр исемлеген төзү.

4.4. Әлеге Нигезләмәнең 4.1 һәм 4.2 пунктларында күрсәтелгән оештыру комитетларының эше аларның утырышларында гамәлгә ашырыла. Әгәр аларда оештыру комитетлары әгъзаларының гомуми саныннан күпчелеге катнашса, утырыш хокукка ия дип санала.

## V. Конкурста жюри

5.1. Конкурска бирелгән иң яхшы эшләрне бәяләү һәм ачыклау, шулай ук җиңүчеләрне билгеләү өчен жюри төзелә.

5.2. Жюри ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт

бюджет учреждениесе вәкилләре, фәнни бергәлек вәкилләре арасыннан жюри рәисе һәм әгъзалары составында кимендә 9 кешедән төзелә. Жюри составы ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

5.3. Конкурска бирелгән эшләрне бәяләгәндә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

бирелгән материалларны бәяләү критерийларына нигезләнеп бәяләүнең объективлыгы;

конфиденциальлек.

5.4. Конкурс эшләрен бәяләүне жюри әгъзалары эксперт бәяләве алымы белән бәяләү критерийларына нигезләнеп башкара.

5.5. Жюри әгъзасы һәр критерий буенча баллар куя, һәм алар кушыла. Һәр критерий буенча баллар саны 10 баллы шкала буенча билгеләнә (0 алып 10 баллга кадәр).

Баллар «Индивидуаль бәяләү кәгазьләре»нә кертелә, жюри әгъзасы имзасы белән таныклана һәм жюри рәисенә тапшырыла (3 нче кушымта).

5.6. Жюри әгъзалары тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 7 бүлегендә күрсәтелгән критерийлар буенча куелган баллларны кушканнан соң, катнашучыларның йомгаклау рейтингы төзелә, ул жюри рәисе һәм әгъзалары тарафыннан имзалана.

5.7. Жюри утырышлары, әгәр аларда жюри әгъзаларының гомуми саныннан 2/3 өлеше катнашса, хокукка ия дип санала.

5.8. Жюри карарлары катнашкан әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

5.9. Жюри карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

## VI. Конкурсны үткәрү шартлары һәм тәртибе

6.1. Конкурс читтән торып үткәрелә. Конкурста катнашучыларның эшләре, 5 төркемдә катнашучыларның эшләреннән тыш, читтән торып 2 этапта карала:

1 этап – муниципаль, муниципаль районнар (шәһәр округлары) башкарма комитетларының архив бүлекләре (идарәләре) тарафыннан 2019 елның 20 мартыннан 15 апреленә кадәр уздырыла;

2 этап – республика, 2019 елның 16 апреленнән 30 апреленә кадәр уздырыла.

6.2. 5 төркем конкурста катнашучыларның эшләре, муниципаль этапта каралмыйча, турыдан-туры конкурсның икенче этабына җибәрелә.

6.3. Конкурсның республика этабы һәр яшь төркеме буенча түбәндәге санда эшләр җибәрүне күздә тота: Татарстан Республикасы муниципаль районнарыннан – һәркайсыннан 1 эш, Түбән Кама муниципаль районыннан – 3 эш, Чаллы шәһәреннән – 4 эш, Казан шәһәреннән – 7 эш.

6.4. Конкурста муниципаль этапта катнашу өчен гаризаны электрон рәвештә җибәрергә һәм/яки кулдан-кулга тапшырырга, Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитетының архив бүлеге (идарәсе) адресына почта аша юлларга кирәк.

6.5. Конкурсның икенче этабында катнашу өчен 2019 елның 25 апреленә кадәр муниципаль районнар (шәһәр округлары) башкарма комитетларының архив

бүлекләре (идарәләре) муниципаль этапта җиңүчеләрнең түбәндәге документлар пакетын электрон рәвештә konkurs.genealogia@yandex.ru электрон почта адресына җибәрәләр һәм/яки кулдан-кулга тапшыралар, Татарстан Республикасы Дәүләт архивы «дәүләт бюджет учреждениесе адресына почта аша (Казан ш., Декабристлар ур., 4) «Минем нәселем» тамгасын куеп юллыйлар:

1 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча гариза;

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә гариза (2 нче кушымта);

конкурс материаллары комплекты (һәр яшь төркемендә иң күбе 1 эш);

муниципаль этапта конкурс йомгаклары беркетмәсе (4 нче кушымта).

6.6. Конкурс материаллары яшь төркемнәренә ярашлы рәвештә түбәндәге форматта тапшырыла:

1 төркем – иҗади эш (гаилә агачы рәсеме, аңлатмалар белән фотоальбомнар, коллажлар, схемалар, плакатлар, аппликация, табигый материал һәм тукымалар кулланып башкарылган күләмле эш һ.б.). Бер катнашучыдан эшләр саны чикләнми;

2 төркем - иҗади эш (гаилә агачы рәсеме, аңлатмалар белән фотоальбомнар, коллажлар, схемалар, плакатлар, аппликация, табигый материал һәм тукымалар кулланып башкарылган күләмле эш һ.б.) һәм, 14 зурлыгындагы Times New Roman шрифты белән язылып, сулдан 2 см, уңнан 1,5 см, өстән һәм астан 2 см буш ара калдырып эшләнгән А4 форматлы 10 биткә кадәр күләмдә (битләр саннары куелу мәҗбүри) язма эш (реферат, эссе, инша һәм һ.б.). Кушымталар күләме чикләнми;

3 төркем – теләсә нинди форматта бирелгән тикшеренү эше (язма эш (аналитик хисап, 14 зурлыгындагы Times New Roman шрифты белән язылып, сулдан 2 см, уңнан 1,5 см, өстән һәм астан 2 см буш ара калдырып эшләнгән А4 форматлы 15 биткә кадәр күләмдә (битләр саннары куелу мәҗбүри)), видеохезмәтләр (гаилә тарихы турында өйдә төшерелгән фильмнар (дәвамлылыгы 10 минутка кадәр), Microsoft Power Point форматындагы презентация (50 слайдка кадәр));

4 төркем – архив документлары нигезендә проект-тикшеренү эше (фәнни хисап, фәнни мәкалә, доклад);

5 төркем – түбәндәге форматта (сайлап алу өчен) конкурс материаллары:

генеалогик схемалар һәм агач рәсемнәре бирелгән язма эшләр (форма: эссе яки мәкалә). Төп тасвирламаның күләме – 14 зурлыгындагы Times New Roman шрифты белән язылып, сулдан 2 см, уңнан 1,5 см, өстән һәм астан 2 см буш ара калдырып эшләнгән А4 форматлы 15 биткә кадәр күләмдә (битләр саннары куелу мәҗбүри), кушымталар күләме чикләнми;

видеоэшләр – гаилә тарихы турында фильмнар (дәвамлылыгы 60 минутка кадәр);

Microsoft Power Point форматында презентация (50 кадәр слайд).

6.7. Конкурска җибәрелгән эшләр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

6.8. Конкурска ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты элек үткәргән генеалогик тикшеренүләр конкурсларында катнашкан эшләр кабул ителми.

6.9. Конкурска материаллар тәкъдим итү авторның аларны конкурсны оештыручының чараларында авторлык хокукларын саклап куллануга рөхсәт бирүен аңлата.

6.10. Җибәрелгән материаллар автор(лар)ның ризалыгы белән Татарстан Республикасының Бердәм архив мәгълүмат системасына кертү өчен файдаланылырга мөмкин.

6.11. Әлеге Нигезләмәнең 6.1 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итү вакыты тәмамланганнан соң җибәрелгән материаллар каралмый.

## VII. Конкурс эшләренең эчтәлегенә карата таләпләр

7.1. 1-5 яшь төркемнәренә караган конкурста катнашучыларның конкурс эшләре эчтәлегенә карата таләпләр:

эшнең максатлары һәм бурычлары булу;

үз нәселе тарихы турында нигезләнгән һәм документлар белән расланган мәгълүмат булу, архив документларына сылтамалар булу, тапшырылган материалларда бирелгән мәгълүматларны исбатлау өчен кирәкле аңлатма язулары һәм тарихи белешмәләр;

ата-бабаларының тормышы, аларның ил, туган як тарихында тоткан урыны турында мәгълүматлар булу (мондый мәгълүмат булган очракта);

үз гаиләсенең милли тамырлары һәм ата-бабаларының кайсы диндә булуы турында мәгълүматлар булу (мондый мәгълүмат булган очракта).

Хезмәттә документлар белән раслана торган мәгълүмат кына түгел, ә гаилә тарихыннан булган һәм документлар белән берничек тә раслап булмый торган теләсә нинди кызыклы фактлар да бәян ителергә мөмкин. Аудиофайл рәвешендә яки аңлаешлы телгә күчерелгән текст рәвешендә тәкъдим ителгән әңгәмәләр, истәлекләр һәм интервью материалларын куллану рөхсәт ителә.

Ата-бабаларының иҗтимагый һәм һөнәри эшчәнлеге, шул исәптән хезмәт ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар булуы турында мәгълүматлар булса, алар да күрсәтелергә мөмкин.

7.2. Эшләр рус һәм (яки) татар телләрендә бирелә.

## VIII. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

8.1. 1 төркем эшләрен бәяләү критерийлары:

конкурсның максатына һәм бурычларына туры килү (0 алып 10 баллга кадәр);

эшнең бизәлешендә оригинальлек һәм иҗади якын килү (0 алып 10 баллга кадәр);

идеяне техник яктан гамәлгә ашыру дәрәҗәсе (0 алып 10 баллга кадәр);

конкурс эшен әзерләүдә мөстәкыйльлек дәрәҗәсе (0 алып 10 баллга кадәр);

китерелгән тарихи фактларның дөреслеге (0 алып 10 баллга кадәр).

8.2. 2-3 төркем эшләрен бәяләү критерийлары:

конкурсның максатына һәм бурычларына туры килү (0 алып 10 баллга кадәр);

китерелгән тарихи фактларның дөреслеге, архив чыганакларыннан файдалану дәрәҗәсе (0 алып 10 баллга кадәр);

гаилә кыйммәтләрен һәм гореф-гадәтләрен ачу дәрәҗәсе (0 алып 10 баллга кадәр);

үз нәселен өйрәнүнең тирәнлеге (0 алып 10 баллга кадәр);

үз фамилиясенең килеп чыгышы турында, ата-бабаларының милли тамырлары, кайсы диндә булуы турында мәгълүматларның булуы һәм нигезләнгәнлеге (0 алып 10 баллга кадәр);

ил һәм туган як тарихында һәм тормышында нәсел вәкилләренең роле турында белемнәрнең тирәнлеге (0 алып 10 баллга кадәр);

эшнең сәнгать ягыннан уңышлы яклары (әдәби тел, бәян итүнең образлылыгы, күрсәтмә материалның бизәлеше сыйфаты) (0 алып 10 баллга кадәр);

файдаланган тарихи чыганакларның күптөрлелеге (документлар, хатлар, гаилә риваятьләре һ.б.ш.) (0 алып 10 баллга кадәр ).

8.3. 4 төркем эшләрен бәяләү критерийлары:

проблеманы өйрәнү тулылыгы, үз фамилиясенең килеп чыгышы, милли тамырлары, ата-бабаларының кайсы диндә булуы, аларның тормышы турында нигезләнгән белешмәләрне дә кертеп (0 алып 10 баллга кадәр);

абруйлы чыганакларга сылтамалар ясап һәм үзе нәтиҗәләргә килеп, тарихи белешмәләргә анализ ясау тирәнлеге (0 алып 10 баллга кадәр);

карый алган барлык төп архив чыганакларының колачлануы, файдаланылган әдәбиятның күләме зур булу (0 алып 10 баллга кадәр);

структураның төгәллеге һәм бәян ителгән материалның эзлеклелеге (0 алып 10 баллга кадәр);

эшнең гамәли һәм фәнни әһәмияте (0 алып 10 баллга кадәр).

8.4. 5 төркем эшләрен бәяләү критерийлары:

конкурсның максатына һәм бурычларына туры килү;

файдаланыла торган тарихи чыганакларның күптөрлелеге (документлар, хатлар, бүләкләр, гаилә риваятьләре һ.б.ш.);

файдаланыла торган архив чыганакларының күптөрлелеге (метрика кенәгәләре, ревизия язмалары, руханилар җыелма басмалары һ.б.ш.);

нәселдә күрсәтелгән буыннар саны (кимендә 3);

үз гаиләңнең килеп чыгышы һәм милли тамырлары турында белемнәрнең тирәнлеге;

төбәк һәм ил тарихында һәм тормышында нәсел вәкилләренең роле турында белемнәрнең тирәнлеге;

нәсел агачының рәсеме (схемасы) һәм аның тасвирламасы булу;

эшнең сәнгать ягыннан уңышлы яклары (әдәби тел, бәян итүнең образлылыгы, рәсем осталыгы) һәм эшнең бизәлешенең техник ягы дөрес башкарылу (бизәлеш таләпләренә туры килү, сылтамалар булу, схемалар, рәсемнәр, фоторәсемнәр кулланылу һ.б.);

гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру һәм үз нәселенең тарихын өйрәнүдә социаль активлык;

эшнең фәнни әһәмияте.

## IX. Җиңүчеләрне билгеләү тәртибе, нәтиҗәләр ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү

9.1. Документлар пакетын тапшырганнан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча жюри утырышы үткәрелә.

9.2. Конкурста җиңүчеләр исемлеге, катнашучыларның йомгаклау рейтингына нигезләнеп, һәр яшь төркеме буенча аерым төзелә.

9.3. Конкурс нәтиҗәләре буенча яшь төркемнәре чикләрендә рейтингта беренче өч урынны алган катнашучылар конкурста җиңүчеләр дип таныла.

9.4. Конкурста җиңүчеләр исемлеге ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән, жюриның йомгаклау утырышы беркетмәсенә нигезләнеп, беркетмәгә кул куелган көннән алып 3 эш көненнән дә соңга калмыйча раслана.

9.5. Конкурста җиңүчеләр исемлекләре боерыкка кул куелган көннән алып 3 эш көне эчендә ТР Архив эше буенча дәүләт архивының рәсми сайтына урнаштырыла.

9.6. Конкурсны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «2016-2021 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү" дәүләт программасында каралган максатчан акчалар хисабына гамәлгә ашырыла.

9.7. Конкурста җиңүчеләр түбәндәгечә бүләкләнә:

1-4 яшь төркемнәрендә: конкурс дипломнары һәм истәлекле бүләкләр: планшет – I урын өчен, кесә телефоны – II урын өчен, электрон китап – III урын өчен.

5 яшь төркемендә: конкурс дипломнары һәм акчалата премияләр: 50 мең сум – I урын өчен, 30 мең сум – II урын өчен, 20 мең сум – III урын өчен.

## X. өстәмә мәгълүмат

10.1. Тәкъдим ителгән эшләргә авторлык хокуклары конкурста катнашучылар тарафыннан саклана.

10.2. Конкурсны оештыручы архив чараларын таныту максатларында, мәгълүмат һәм презентация материалларын ясау өчен конкурс эшләрен, шул исәптән конкурска гаризаларга беркетеп җибәрелгән фотоларны, видеороликларны һәм башка документларны авторлык хокукларын саклап куллану хокукын үзендә калдыра.

10.3. Җиңүчеләр исемлегенә кермәгән конкурста катнашучыларның барысына да конкурста катнашучылар сертификатлары бирелә, алар җиңүчеләр исемлеге урнаштырылганнан соң 10 эш көне эчендә катнашучының E-mail адресына электрон рәвештә җибәрелә.

2019 елда «Минем нәселем" республика генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

2019 елда
«Минем нәселем" республика генеалогик тикшеренүләр конкурсында катнашуга гариза

| | |
|---|---|
| Фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| Катнашучының яше | |
| Катнашучы укый торган белем бирү оешмасы; Катнашучының эш урыны | |
| Катнашучының яшәү урынының индексы белән тулы адресы | |
| Катнашучының элемтә өчен телефоннары | |
| Катнашучының E-mail адресы | |
| Конкурс эшенең исеме | |
| Эш тәкъдим ителгән яшь төркеме | |

2019 елда «Минем нәселем" республика
генеалогик тикшеренүләр конкурсы
турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Шәхси мәгълүматларны
эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга
рөхсәт

“Минем нәселем” республика генеалогик тикшеренүләр конкурсындагы түбәндәге күләмдә шәхси мәгълүматларымны, “Шәхси мәгълүматлар турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга (аларны миннән һәм/яки теләсә кайсы өченче заттан алуны да кертеп) рөхсәт бирәм:

Эшкәртелә торган персональ мәгълүматлар исемлеге (Ф.И.А.и. (соңгысы – булган очракта), җенес, туу датасы һәм урыны, гражданлык, шәхесне таныклый торган документның реквизитлары (документның төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон номеры), электрон почта адресы)

_______________________________________________________________

(Ф. И. А.и. (соңгысы – булган очракта), имза)

____________________

(дата)

2019 елда «Минем нәселем" республика генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

## 1 төркем эшләрен индивидуаль бәяләү кәгазьләре

| Гариза бирүченең фамилиясе, конкурс эшенең исеме һәм эшне тәкъдим итү форматы | |
|---|---|
| Критерийлар | 0 алып 10 баллга кадәр |
| конкурсның максатына һәм бурычларына туры килү | |
| эшнең бизәлешендә оригинальлек һәм иҗади якын килү | |
| идеяне техник яктан гамәлгә ашыру дәрәҗәсе | |
| конкурс эшен әзерләүдә мөстәкыйльлек дәрәҗәсе | |
| китерелгән тарихи фактларның дөреслеге | |
| БАРЛЫГЫ | |

## 2-3 төркем эшләрен индивидуаль бәяләү кәгазьләре

| Гариза бирүченең фамилиясе, конкурс эшенең исеме һәм эшне тәкъдим итү форматы | |
|---|---|
| Критерийлар | 0 алып 10 баллга кадәр |
| конкурсның максатына һәм бурычларына туры килү | |
| китерелгән тарихи фактларның дөреслеге, архив чыганакларыннан файдалану дәрәҗәсе | |
| гаилә кыйммәтләрен һәм гореф-гадәтләрен ачу дәрәҗәсе | |
| үз нәселен өйрәнү тирәнлеге | |
| үз фамилиясе барлыкка килү турында, милли тамырлары, ата-бабаларының кайсы диндә булуы турында мәгълүматларның булуы һәм аларның нигезләнгәнлеге | |
| ил һәм туган як тарихында һәм тормышында нәсел вәкилләренең роле турында белемнәрнең тирәнлеге | |
| эшнең сәнгать ягыннан уңышлы яклары (әдәби тел, бәян итүнең образлылыгы, күрсәтмә материалның бизәлеш сыйфаты) | |
| файдаланылган тарихи чыганакларның күптөрлелеге (документлар, хатлар, гаилә риваятьләре һ.б.ш.) | |
| БАРЛЫГЫ | |

## 4 төркем эшләренең индивидуаль бәяләү кәгазьләре

| Гариза бирүченең фамилиясе, конкурс эшенең исеме һәм эшне тәкъдим итү форматы | |
|---|---|
| Критерийлар | 0 алып 10 баллга кадәр |
| проблеманы өйрәнү тулылыгы, үз фамилиясенең килеп чыгышы, милли тамырлары, ата-бабаларының кайсы диндә булуы, аларның тормышы | |

| | |
|---|---|
| турында нигезләнгән белешмәләрне дә кертеп | |
| абруйлы чыганакларга сылтамалар ясап һәм үзе нәтиҗәләргә килеп, тарихи белешмәләргә анализ ясау тирәнлеге | |
| карый алган барлык төп архив чыганакларының колачлануы, файдаланылган әдәбиятның күләме зур булу | |
| структураның төгәллеге һәм бәян ителгән материалның эзлеклелеге | |
| эшнең гамәли һәм фәнни әһәмияте | |
| БАРЛЫГЫ | |

5 төркем эшләренең индивидуаль бәяләү кәгазьләре

| Гариза бирүченең фамилиясе, конкурс эшенең исеме һәм эшне тәкъдим итү форматы | |
|---|---|
| Критерийлар | 0 алып 10 баллга кадәр |
| Конкурсның максатына һәм бурычларына туры килү | |
| Кулланыла торган тарихи чыганакларның күптөрлелеге (документлар, хатлар, бүләкләр, гаилә риваятьләре һ.б.ш.) | |
| Файдаланыла торган архив чыганакларының күптөрлелеге (метрика кенәгәләре, ревизия язмалары, руханилар җыелма басмалары һ.б.ш.) | |
| Нәселдә күрсәтелгән буыннар саны (кимендә 3) | |
| Үз гаиләңнең килеп чыгышы һәм милли тамырлары турында белемнәрнең тирәнлеге | |
| Төбәк һәм ил тарихында һәм тормышында нәсел вәкилләренең роле турында белемнәрнең тирәнлеге | |
| Нәсел агачының рәсеме (схемасы) һәм аның тасвирламасы булу | |
| Эшнең сәнгать ягыннан уңышлы яклары (әдәби тел, бәян итүнең образлылыгы, рәсем осталыгы) һәм эшнең бизәлешенең техник ягы дөрес башкарылу (бизәлеш таләпләренә туры килү, сылтамалар булу, схемалар, рәсемнәр, фоторәсемнәр кулланылу һ.б.) | |
| Гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру һәм үз нәселенең тарихын өйрәнүдә социаль активлык | |
| Фәнни әһәмияте | |
| БАРЛЫГЫ | |

«___» ___________, 2019 ел _________________________ /___________________________________

Төзелү датасы Җюри әгъзасы имзасы Бәяләмә бирүче имзасын аңлатып язу

2019 елда «Минем нәселем" республика генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында нигезләмәгә
4 нче кушымта

2019 елда
«Минем нәселем" республика генеалогик тикшеренүләр конкурсының
муниципаль этабында жюри утырышы
БЕРКЕТМӘСЕ

Татарстан Республикасы _______________ муниципаль районы (шәһәр округы)
башкарма комитетның архив бүлеге (Идарәсе)

Архив бүлегенең почта адресы, e-mail_____________________________________
(индексы, муниципаль район,
_____________________________________________________________________
шәһәр, район, урам, йорт)

Муниципаль архив җитәкчесенең Ф.И.А.и. (тулысынча), телефон
_____________________________________________________________________

Конкурсның муниципаль этабы жюри рәисе Ф.И.А.и. (тулысынча)
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________

Утырыш датасы ________________________________________________________

Конкурсның республика этабына түбәндәге эшләрне тәкъдим итәргә:

1 яшь төркеме_____________________________________________________
(эшнең исеме) (авторның Ф.И.А.и., авторның туган елы)

2 яшь төркеме_____________________________________________________
(эшнең исеме) (авторның Ф.И.А.и., авторның туган елы)

3 яшь төркеме_____________________________________________________
(эшнең исеме) (авторның Ф.И.А.и., авторның туган елы)

4 яшь төркеме_____________________________________________________
(эшнең исеме) (авторның Ф.И.А.и., авторның туган елы)

Жюри әгъзаларының имзалары:
(имза) (Ф.И.А.и., вазыйфа)_______________________________

(имза) (Ф.И.А.и. вазыйфа) _______________________________

(имза) (Ф.И.А.и. вазыйфа) _______________________________

Беркетмә расланды_______________________________________
(муниципаль этапта жюри рәисе имзасы)